ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЕ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**от 03.03.2020** **№ 269**

**Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмалары эшчәнлеген 2020 нче елга финанслау нормативларын раслау турында»гы 2019 нчы елның 25 нче ноябрендәге 2099 нчы номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясенең 2012 нче елның 29 нчы декабрендәге 273 нче номерлы «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Законының 99 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турындагы» 2003 нче елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 бүлегенең 11 пункты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 нчы елның 2 нче июлендәге 546 нчы номерлы «Мәктәпкәчә белем бирү муниципаль оешмалары эшчәнлеген норматив финанслау турындагы» карары һәм «Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, «Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмалары эшчәнлеген финанслау нормативларын раслау турындагы» 2019 нчы елның 25 нче ноябрендәге 2099 нчы номерлы карарының 3 нче кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 15 нче номерлы юлдагы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының «Әкият» Ислейтар балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе»н «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының «Айгөл» Семиозерка балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе»нә алмаштырырга;

2) 21 нче юлдагы «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының «Ландыш» Мәмдәл балалар бакчасы» муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе»н «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Х.Вахит исемендәге Мәмдәл урта гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе» нә алмаштырырга;

2. Әлеге карарны Биектау муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ адресы буенча һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында: http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча урнаштырып халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары Р.Р. Сабирҗановка йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Ф. Шәйдуллин